| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

«25» июль, 2016 ел Олы Кайбыч ав. № 44

Кайбыч муниципаль район Советының 2011 елның 26 апрелендәге 52 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советының X съезды йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының уртак чаралар планының 6 пунктын үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2011 елның 26 апрелендәге 52 номерлы Кайбыч муниципаль район Советы карарына (Кайбыч муниципаль район Советының 2012 елның 03 ноябрендәге 140 номерлы, 2014 елның 26 маендагы 222номерлы , 2015 елның 22 июнендәге 276 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Юридик эш өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибен һәм күләмнәрен яңа кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә һәм аны 14 нче кушымта дип санарга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 августыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе Р. Г. Айзатулловага йөкләргә.

**Совет Рәисе,**
**Кайбыч муниципаль**
**районы Башлыгы** **А.И.Рәхмәтуллин**

Кайбыч муниципаль районы
Советының2016 е. 25.07
44 номерлы карарына кушымта

# ЮРИДИК ЭШ ӨЧЕН АЙЛЫК ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТӘРТИБЕН ҺӘМ КҮЛӘМНӘРЕ

1. Айлык өстәмә түләү хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларны югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә) булган муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларына билгеләнә һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең хокукый актлары белән билгеләнә.

2. Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, аларны юрист яки югары юридик белемгә ия булган башкаручы сыйфатында визалау кергән муниципаль хезмәткәргә өстәмә түләү вазыйфаи окладның 90 проценты күләмендә билгеләнә.

3. Өстәмә түләүне исәпләү ай саен башкарыла һәм җирле үзидарә органының хезмәт өчен түләү фонды акчалары хисабына акчалата эш хакы белән бергә түләнә.

4. Муниципаль хезмәткәргә өстәмә түләү билгеләү турындагы карар ул анда хезмәт итә торган җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.